# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**

**утыз алтынчы утырыш**

**15 ноябрь 2023ел** **№ 141** **Шәтке авылы**

**Җир салымы турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлегенең Уставына таянып, Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге советы **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләүле җир салымын билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Җир салымының кадастр бәясеннән салым ставкаларын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

А) Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә торак пунктларда авыл хуҗалыгы файдалануы зоналары составындагы һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен кулланыла торган җир кишәрлекләренә карата 0,3 процент;

Б) торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) 0,3 процент;

В) шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек, индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,1 процент;

Г) административ һәм офис биналары, мәгариф, фән, сәламәтлек саклау һәм социаль тәэмин итү, физик культура һәм спорт, сәнгать, дин белән шөгыльләнү өчен каралган җир кишәрлекләренә карата 0,1 процент;

Д) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланылмый торган җирлекләрдә авыл хуҗалыгы куллану зоналары составындагы җирләргә карата 0,5 процент;

Е) башка җир кишәрлекләренә карата 1,5 процент;

Ж) гомуми файдаланудагы 1-3 категорияле автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата 0,05 процент;

З) оборона, иминлек һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән җир кишәрлекләренә карата 0,3 процент.

3. Салым ташламаларын түбәндәгечә калдырырга:

3.1. 100% күләмендә җир салымын түләүдән азат итү рәвешендә:

А) ялгыз яшәүче 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнар;

Б) ятим балалар;

В) стихияле бәла-казалардан зыян күргән гражданнар;

Г) Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары, шулай ук сугыш хәрәкәтләре ветераннары һәм инвалидлары;

Д) сугышчан хәрәкәтләр алып барылган Әфганстан Республикасында һәм башка илләрдә интернациональ бурычын үтәгән гражданнарга;

Е) оешмалар һәм учреждениеләргә - зиратлар, үләт базлары, граждан күмүләре, каты көнкүреш калдыклары полигоннары белән мәшгуль җир кишәрлекләренә карата;

Ж) янгыннан саклау буенча иҗтимагый берләшмәләр әгъзалары һәм ирекле янгын сүндерүчеләр;

З) халыкны су белән тәэмин итү өчен скважиналар һәм су башнялары урнаштырылган җир кишәрлекләре; гидротехник корылма; су җыю челтәренең каптажын реконструкцияләү өчен; Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл җирлеге территориясендәге коммуналь хезмәт күрсәтү өчен;

И) муниципаль учреждениеләргә - әлеге карарның А пунктчасында күрсәтелгән 2 пунктыннан тыш, мәйданнар, урамнар, юллар, автомобиль юллары белән биләнгән гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә карата яр буйлары, мәдәният һәм ял парклары, аллеялар, скверлар, спорт мәйданчыгы, спорт паркы, балалар мәйданчыгы, тренажер мәйданчыгы;

К) Теләче муниципаль районы Советы карары нигезендә төзелгән муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать парклары яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә төзелгән индустриаль (сәнәгать) парклар биләгән җир кишәрлекләре, җир кишәрлеге хуҗалары, резидентларны җир кишәрлегенә эшчәнлек алып бару өчен җәлеп иткән очракта, башка очракларда җир салымыннан азат итү кулланылмый;

Л) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категорияләре булган җир кишәрлекләре милекчеләре, рөхсәт ителгән файдалану рәвеше белән: плотина урнаштыру өчен.

3.2. Җир салымын түләүдән өлешчә азат итү рәвешендә:

А) федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан, җирле бюджеттан финанслана торган Шәтке авыл җирлеге территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте һәм идарә органнарына, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә, җирнең кадастр бәясенең 0,52 проценты күләмендә салымның киметелгән ставкасын куллану рәвешендә;

Б) шәхси ярдәмче хуҗалык өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата салым түләүдән тулысынча азат итү рәвешендә салым түләүчене сайлау буенча бер җир кишәрлеге өчен:

В) ирекле янгын сүндерүчеләргә һәм янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләренә, салым чоры дәвамында ирекле янгын командалары (дружиналар) составында янгыннар сүндерүдә турыдан-туры катнашу шарты белән.

4. Билгеләргә:

4.1.Салым чоры дип календарь ел таныла.

4.2.Салым түләүче оешмалар өчен хисап чорлары дип беренче квартал, икенче квартал һәм календарь елның өченче кварталы таныла.

5. Гамәлдән чыккан дип танырга:

-Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 24.11.2014 елның 121 нче номерлы «Җир салымы турында» карары;

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 08.05.2015 елның 146 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 24.11.2014 елның 121 нче номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карары;

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 23.06.2015 елның 157 нче номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 24.11.2014 елның 121 нче номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карары;

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 23.06.2015 елның 157-1 нче номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 24.11.2014 елның 121 нче номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карары;

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 25.07.2017 елның 39 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 24.11.2014 елның 121 нче номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карары;

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 29.10.2020 елның 9 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 24.11.2014 елның 121 нче номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карары;

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 11.05.2021 елның 41 нче номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 24.11.2014 елның 121 нче номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карары;

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 20.10.2023 елның 133 нче номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 24.11.2014 елның 121 нче номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карары;

6. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы
Шәтке авыл җирлеге башлыгы — Ф.Г. Кадыйров

СОВЕТ ШАДКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ